**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «22» июненнән № 266

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2011 елның 10 февралендәге 63 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2011 елның 10 февралендәге 63 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктта:

2 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«мәдәният өлкәсе хезмәткәрләренә - торак, җылылык, ут өчен түләү. Күрсәтелгән социаль ярдәм чарасы шулай ук пенсиягә чыккан, 60 һәм 55 яшькә җиткән гражданнарга (ир-атлар һәм хатын-кызлар), шулай ук 2018 елның 31

декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килгән, әмма 60 һәм 55 яшькә җитмәгән (ир-атлар һәм хатын-кызлар), әлеге хезмәткәрләр авыл җирендә яшәүче һәм авыл җирлегендә урнашкан муниципаль мәдәният учреждениеләрендә 10 елдан да ким эшләмәгән гражданнарга бирелә»;

түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

«Торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң, күрсәтелгән бурыч буенча түләү 90 көн эчендә җайга салынганда, социаль ярдәм чараларын бирү шундый билгеләнешкә мөрәҗәгать иткән көннән башкарыла.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәгеге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:/pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль эшләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов